**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НИКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**422627 , с.Никольское ,**
**ул. Центральная , д 35**
**тел: 4-31-44**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКОЛЬСКИЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**422627 Никольский авылы,**
**Эзэкурамы , 35 нчыйорт,**
**Тел : 4-31-44**

---

**2020 елның 14 феврале** **2 номерлы**

# КАРАР

**«Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Никольский авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 12 апреленәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2014 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 декабрендәге 880 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» карары, Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының «Лаеш муниципаль районы башкарма органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2010 елның 13 декабрендәге 2027 номерлы карары нигезендә карар бирәм:

1.«Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Никольский авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 12 апреленәге 4 номерлы карарына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталына Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Никольский авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **Э.Х.Алеев**

Татарстан Республикасы Лаеш
муниципаль районы Никольский
авыл җирлеге Башкарма
комитетының  2020 елның 14
февралендәге 2 номерлы
карарына кушымта

**«Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Никольский авыл җирлеге башкарма комитетының   2019 елның 12 апреленәге 4 номерлы  карарына үзгәрешләр**

**1.** 1. 1.5 пунктының 3 абзацында «планлаштыру структурасы элементы (кирәк булганда), урам-юл челтәре элементы» сүзләрен «урам-юл челтәре элементы һәм (яисә) планлаштыру структурасы элементының исеме (кирәк булганда) сүзләренә алмаштырырга.

2. 1.5 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«адресация объекты - капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән адресация объектлары исемлегендә каралган башка объект;